# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

Утлы, газлы коралны, сугыш кирәк-яракларын һәм сиптергеч баллоннарны сатып алу, саклау һәм куллану кагыйдәләрен бозган өчен административ җаваплылык турында

Әлеге Закон Утлы, газлы коралны, сугыш кирәк-яракларын һәм сиптергеч баллоннарны сатып алу, саклау һәм куллану кагыйдәләрен бозуга каршы көрәшне көчәйтүгә юнәлтелгән.

1 статья

Гражданнар тарафыннан һәм, милек рәвешләренә карамастан, предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар тарафыннан утлы, газлы корал, сугыш кирәк-яраклары һәм сиптергеч баллоннар билгеләнгән сату тәртибен бозып сатылса, әгәр әлеге гамәлләр җинаять җәзасы составына кермәсә,-

күрсәтелгән предприятиеләрнең, учреждениеләрнең, оешмаларның урындагы затларына - биш минималь хезмәт хакы күләменә кадәр, гражданнарга, утлы, газлы коралны, сугыш кирәк-яракларын һәм сиптергеч баллоннарны, шулай ук законсыз сатудан алынган керемнәрне конфискацияләп яисә аннан башка гына, өч минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына.

Әлеге статьяның беренче өлешендә күрсәтелгән хокук бозулар өчен административ җәза чаралары күрелгәннән соң да бер ел эчендә әлеге гамәлләр кабатланса,-

урындагы затларга - ун минималь хезмәт хакы күләменә кадәр, гражданнарга, утлы, газлы коралны, сугыш кирәк-яракларын һәм сиптер-

геч баллоннарны, шулай ук законсыз сатудан алынган керемнәрне конфискацияләп, биш минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына.

2 статья

Сәүдә предприятиеләре /оешмалары/ хезмәткәрләре тарафыннан утлы, газлы коралны, сугыш кирәк-яракларын һәм сиптергеч баллоннарны сату кагыйдәләре бозылса, әгәр әлеге гамәлләр җинаять җәзасы составына кермәсә,-

аларга биш минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына.

Әлеге статьяның беренче өлешендә күрсәтелгән хокук бозулар өчен административ җәза чаралары күрелгәннән соң да бер ел эчендә әлеге гамәлләр кабатланса,-

ун минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына.

3 статья

Гражданнар тарафыннан һәм, милек рәвешләренә карамастан, предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар тарафыннан утлы, газлы коралны, сугыш кирәк-яракларын һәм сиптергеч баллоннарны сатып алу, саклау, йөртү кагыйдәләре бозылса, шулай ук алар урынсыз кулланылса яисә гражданнар утлы яки газлы коралны башка кешеләргә бирсәләр, әгәр әлеге гамәлләр җинаять җәзасы составына кермәсә,-

әлеге предприятиеләрнең, учреждениеләрнең, оешмаларның урындагы затларына – биш минималь хезмәт хакы күләменә кадәр, гражданнарга, утлы, газлы коралны, сугыш кирәк-яракларын һәм сиптергеч баллоннарын конфискацияләп, яки аннан башка гына, өч минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына.

Әлеге статьяның беренче өлешендә күрсәтелгән хокук бозуларның берәрсе өчен административ җәза чаралары күрелгәннән соң да бер ел эчендә шушы гамәлләр кабатланса, - урындагы затларга – ун минималь хезмәт хакы күләменә кадәр, гражданнарга, утлы, газлы коралны, сугыш кирәк-яракларын, сиптергеч баллоннарны конфискацияләп, биш минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына.

4 статья

Гражданнарның утлы яисә газлы коралны теркәүдән/кабат теркәүдән/ баш тартулары,эчке эшләр органнарында утлы яисә газлы коралны исәпкә алу кагыйдәләрен бозулары өчен,-

өч минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына.

5 статья

Билгеләнгән тәртипне бозып, утлы һәм газлы коралдан аткан өчен, -

гражданнарга биш минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына яисә, хезмәт хакының 20 процентын тотып калып, бер айдан ике айга кадәр төзәтү эшләренә җәлеп ителә, ачылган эшнең торышына карап, тәртип бозучының шәхесен исәпкә алып, әлеге чараларны куллану җитәрлек түгел дип табылган очракта,-

коралны һәм сугыш кирәк-яракларын конфискацияләп яисә аннан башка гына,тәртип бозучы унбиш тәүлеккә кадәр административ рәвештә кулга алына.

6 статья

Даими рәвештә җәмәгать тәртибен бозучы,спиртлы эчемлекләр, наркотик матдәләр куллануучы яисә психик авырулардан интегүче затлардагы  утлы һәм газлы коралны саклау өчен бирелгән рөхсәт эчке эшләр органы тарафыннан юкка чыгарыла.

7 статья

Утлы, газлы коралны саклау өчен бирелгән рөхсәт юкка чыгарылган урындагы затларның һәм гражданнарның утлы, газлы коралны һәм сугыш кирәк-яракларын сату турында эчке эшләр органнарының күрсәтмәләрен үтәмәүләре өчен,-

утлы, газлы коралны һәм сугыш кирәк-яракларын тартып алып, аларның хакын иясенә кире кайтарып, ике минималь хезмәт хакы күлә-

менә кадәр штраф салына.

8 статья

Әлеге Законда күрсәтелгән административ хокук бозулар турында беркетмә Татарстан Республикасы эчке эшләр органнарының вәкаләтле урындагы затлары тарафыннан төзелә һәм җиде көн эчендә халык суды карамагына җибәрелә.

9 статья

Эшләр вәкаләтле органнар тарафыннан каралганчы, эчке эшләр органнары әлеге Законда билгеләнгән административ хокук бозулар турындагы материаллар нигезендә утлы, газлы коралны тартып алырга хаклы.

10 статья

Әлеге Законның 7 статьясы нигезендә тартып алынган ау мылтыгы һәм газлы корал комиссиягә куеп сату өчен сәүдә оешмаларына бирелә. Сатудан килгән акчалар корал иясенә кире кайтарып бирелә.

Әлеге Закон нигезендә конфискацияләнгән башка төр утлы, газлы, сугыш кирәк-яраклары эчке эшләр органнарына тапшырыла.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1993 елның 18 мае
N 1868-XII